ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының һәм суд участокларының гомуми саны турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

---

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының һәм суд участокларының гомуми саны турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының һәм суд участокларының гомуми саны турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын бәяләмә бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм килештерү өчен Россия Федерациясе Югары Судына җибәрергә.

3. «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының һәм суд участокларының гомуми саны турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең бәяләмәсен һәм закон проектын Россия Федерациясе Югары Суды белән килештерүне раслаучы документны алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Күрсәтелгән федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты И.И. Гыйльметдиновны билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 11 июле
№ 2978-V ДС